ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

2021 елның «27» октябре №1009

2022 елга «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 ел, 14 декабрь, 854 нче карары һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. 2022 елга расларга:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкага йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

В.С. Санатуллин
5-12-22

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 27 октябрендә кабул ителгән 1007 номерлы карары белән расланды

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар

| Программаның юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына сунарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Укуның өч еллык срогы | Укуның дүрт еллык срогы | Укуның биш еллык срогы | Укуның җиде еллык срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Нәфис сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Нәфис сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрад-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрад-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театраль сәнгать | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театраль сәнгать | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |